**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» гыйнвар, 2020 ел № 28

Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2021 елның 1 кварталына салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен раслау турында

Россия Федерациясе Торак коды, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2020 елның 29 сентябрендәге «Россия Федерациясе субъектлары буенча 2021 елның 1 кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 557/пр боерыгына таянып, Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Гражданнарны наем шартнамәсе буенча торак урын бирелүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен максималь күрсәткечләр билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 601 490 сум
1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 2 038 260 сум
1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 2 620 620 сум
1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 3 494 160 сум
1.1.5. Биш кешелек гаилә өчен - 4 367 700 сум
1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 5 241 240 сум
1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен - 6 114 780 сум

1.2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең максималь күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 20 983 сум

1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен - 13 353 сум

1.2.3. Өч кешелек гаилә өчен - 11 446 сум

2. Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдалануны социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондын исәпкә кую һәм аларга торак урыннары бирү максатларында аз керемле дип тану өчен файдаланырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хәбибуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1633605397